# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 14 «20» декабрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Бәйрәкә авыл җирлегендәге Бәйрәкә
торак пунктында 2022 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципал районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Бәйрәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, ветераннар һәм Бөек ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләреннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә, түләү суммасын 250 (ике йөз илле) сумга киметеп, 2 төркем инвалидларга үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- юлларны грейдерлаштыру һәм кардан чистарту (ягулык сатып алу, трактористы белән техника арендалау, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылының Пушкин урамындагы юл-урам челтәрен норматив торышка китерү (смета нигезендә юл төзү: вак ком-таш катнашмасы, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, алып кайту, салу, эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылының административ бина территориясен төзекләндерү (койма урнаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү; агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту);
- Бәйрәкә авылындагы 8 Март урамында урнашкан зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Бәйрәкә авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклаучы лампалар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү);
- Бәйрәкә авылында корыган агач, куакларны кисү, авыл территориясен җыештыру (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар монументына алып баручы парад баскычын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Бәйрәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына

урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы,
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина